Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

04.12.2023 Менделеевск ш. № 708

Җир кишәрлегеннән файдалануны
шартлы рөхсәт ителгән төргә
рөхсәт бирү турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының 2023 елның 20 октябрендәге мөрәҗәгатен һәм тәкъдим ителгән материалларны карап чыгып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясына, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының 2018 елның 2 августындагы 60 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә”, җир кишәрлегеннән файдалануны шартлы рөхсәт ителгән төргә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча 2023 елның 1 декабрендәге гавами тыңлаулар беркетмәсе һәм нәтиҗәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты,

К А Р А Р  Б И Р Ә:

1. Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы, “Менделеевск шәһәре, “Менделеевск шәһәре” муниципаль берәмлеге адресы буенча урнашкан 16:27:110144:382 кадастр номеры булган җир кишәрлеген рөхсәт ителгән куллану төре «Территорияне төзекләндерү» дән «Кибет»кә үзгәртеп, файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирергә

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга https://mendeleevsk.tatarstan.ru /.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Ф. Искаковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Искәндәров

Килештерелде:

Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева

башкаручы. Хәбиров Р.З.
8(85549)2-01-99